





XVIII гасырда милли үзаңның үсүе татар халкы алдына күп төрле чишеләсе мәсьәләләр куя. Халкыбызның алдынгы вәкилләре татар тарихын өйрәнүгә керешә. XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында милләтебезнең тарихына багышланган шактый хезмәтләр басылып чыга. Биредә Г. Әхмәрев, М. Рәмзи, Р. Фәхретдин, З. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, Һ. Атласиларның китапларын атап була. Әмма татар тарихы фәнни нигездә өйрәнүчеләрнең беренчесе, һичшиксез, Шиһабетдин Мәрҗани. Аның татар тарихы буенча төп хезмәте булып «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) исемле ике томлык китабы тора. Бу китапның беренче томы 1897 елны Казанда Б. Л. Домбровский нәшриятында, ә икенче томы 1900 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә*. Ш. Мәрҗани бу хезмәтендә Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм татар ханлыкларының тарихын язып, киләчәк буын тарихчыларына үз әсәрен бер программа шикелле тәкъдим итә. Аннан соңгы тарихчылар, нигездә, ул ярган юлдан баралар.

СССР заманында тарихны сәясиләштерү татар тарихын тар кысалар эченә кертте. Безнең этник һәм сәяси тарихыбызның күп мәсьәләләре Болгар дәверенә һәм Болгар дәүләте территориясенә генә кайтарып калдырылды. Казан ханлыгы чоры белән шөгыльләнергә бераз ирек булса да, Алтын Урда тарихын өйрәнү хупланмады. XIII-XIV гасырлар татар тарихы «Алтын Урда составында Болгар», «Алтын Урданың

* Без кулланганы, профессор Әхмәт Тимер тарафыннан 1997 елда Анкара университетының басмаханәсендә репринт рәвешендә нәшер ителгәне (кара: Temir A. Şehabeddin Mercani. Hayat, Şahsiyeti, Eserleri // Önsöz. Şehabeddin Mercani. Müstefadül-Ahbar fi ahvali Kazan ve Bulgar. Türk Bas lm. – Ankara, 1997. – S. 93-117).

EV_1_08.indb 179 13.05.2008 12:20:43

таркалуы» кебек берьяклы темалар аша гына өйрәнелде. Әлбәттә, бәяләмәләрне биргәндә Алтын Урда дәүләтен начар яктан гына тасвирлау мәҗбүри булган. Мондый тыю бигрәк тә Татарстан тарихчыларына кагылды. Илдәге сәяси үзгәрешләр тормышыбызның һәр тармагына алып килгән ирек тарих фәнен дә читләтеп үтмәде. Татар тарихчылары эзләнүләрен актив рәвештә Алтын Урда һәм башка ярым тыелган темаларга юнәлттеләр.

Безнең бүгенге профессиональ тарихчыларыбызның татар халкының урта гасырлардагы тарихына концептуаль карашлары нәрсәдән гыйбарәт соң?

Беренчедән, татарларны милләт буларак формалаштыручы төп фактор итеп, Алтын Урда дәүләте күрелә. Икенчедән, милләтебезнең этник, мәдәни, сәяси тамырлары Төрки каһанлыгына, Караханиларга, Харәземгә, Хәзәр каһанлыгына, кимәкләргә, кыпчакларга һәм болгарларга бәйләп өйрәнелә. Әгәр без Ш. Мәржанинең телгә алынган тарихи хезмәтенә күз салсак, аның нигезендә дә шушы ук концепциянең яткынын күрәбез.

Мәржани үзе яшәгән чорда ук зур дин галиме һәм тарихчы буларак таныла. Ватаныннан тыш ул Урта Азиядә, Төркиядә, гарәп илләрендә, Һиндстанда да билгеле булган[1]. Ш. Мәржани В. В. Радлов, Х. Фәезханов, И. Ф. Готвальд кебек мәшһүр галимнәр белән тыгыз мөнәсәбәттә торган[2]; аның хезмәтләре Н.И. Ильминский, В. В. Вельяминов-Зернов, С. М. Шпилевский, Н. П. Загоскин, Н. Ф. Катанов, И. Н. Смирнов, Н. И. Ашмарин, Е. А. Малов һәм башкаларның да игътибарын җәлеп иткән[3].

Ш. Мәржани чыганаклардан өзекләр генә китереп калмый, ә аларны чагыштыра, анализлый. Язма чыганаклар белән бергә ул иске татар тәңкәләрен, кабер ташларындагы язуларны, фольклор мәгълүматын куллана. Әсәреннән күренгәнчә, Ш. Мәржани рус чыганакларындагы мәгълүматтан да хәбәрдар булган. Мәсәлән, ул Куликово кыры, Угра елгасы бәрелешләрен, рус елъязмаларында телгә алынган татар-рус мөнәсәбәтләренә кагылышлы башка вакыйгаларны тасвирлый. Әмма Мәржани ул мәгълүматны турыдан рус елъязмаларыннан түгел, ә рус тарихчылары хезмәтләреннән алган. Монда аның фәнни өйрәнү ысулларына һәм тарихи карашларына Х. Фәезханов һәм В. В. Радловның тәэсире сизелә.

«Мөстәфадел-әхбар»да кулланылган чыганаклар тикшерелеп, аларның исемлеге дә төзелгән[4]. Шулардан Алтын Урда тарихын өйрәнү җәһәтеннән иң кыйммәтле әсәрләр — Ибне Хәлдун, Ибне Баттута, Ибне Гарәбшаһ хезмәтләре. Телгә алынган шәхесләр XIV-XV гасырларда яшәп, Алтын Урда дәүләтенең замандашлары булганнар, ә соңгы ике автор Алтын Урдага сәяхәт тә кылган. Ш. Мәржани шулай ук Мирхонд, Ибнел-Вәрди, Нәбакти, Әбелгази хан, Рәшидеддин, Мөхәммәд Риза әфәнде, Мөхәммәд Шабанкарәи, Гатауллаһ бине Яхъя Нугайзадә әфәнде һәм башкаларның хезмәтләренә еш кына мөрәҗәгать итә.

Ш. Мәржани татар язма чыганакларын да куллана. Мәсәлән, Алтын Урда дәвереннән калган ике ярлыкның — Туктамыш ханның Польша короле Ягайлага язган хат-ярлыгы һәм Тимур-Котлык ярлыгының — тулы текстларын китерә. Ул хаклы рәвештә аларның татар телендә «уйгыр каләме» белән язылганлыкларын күрсәтә. Моннан башка, Ш. Мәржани халык арасында таралган әйтем һәм мәкальләрне дә китереп, теге яки бу вакыйганың чынлыгына өстәмә дәлил итеп куллана. Мәсәлән, «үзбәк халкы эчендә “Бәрдибәк тә киселде”, дигән сүз мәшһүрдер», яки «нугай халкында “дин Үзбәктән таралды” дигән сүз билгеле», дип әйтә, «Идел туңса, кем кичмәс, Идегү булса, кем китмәс», дигән мәкаль яшәгәнлеген искәртә. Үз фикерләрен дәлилләү өчен галим фарсы телендәге бәет һәм шигырьләрдән дә оста файдалана.

Галим үз хезмәтендә нумизматика материалларын да киң куллана. Ул Сарай, Болгар, Кырым, Урда, Гөлестан, Хаҗитархан, Азак, Маҗар, Харәзем шәһәрләрендә сугылган тәңкәләр

EV_1_08.indb 180 13.05.2008 12:20:43

турында әйтеп үтә. Мәсәлән, татар ханнары турында сөйләгәндә, галим тәңкәләрнең күп табылуын искәртә. Ул ханнарның исемнәре: Мәңгү-Тимур, Туда-Мәңгү, Туктай, Кульна, Нәүрүзбәк, Килдебәк, Хызыр, Урда Мәлик, Мөрид, Тулунбәк, Туктамыш, Кадир Бирде, Борак, Дәрвиш, Чәкрә, Фулад-Тимур, Тимур, Гыяседдин Бүләк, Алыбхан Хуҗа, Чиркәсбәк, Гыяседдин Агабәк, Базарчы. Соңгы дүртесе турында Мәрҗани хаклы рәвештә «бу ханнар Җүҗи олысының бөтенесенә хан булмаган» — дип әйтә.

Шиһабетдин Мәрҗанинең ул вакытта аякка яңа басып килгән нумизматика фәненең алымнарын дөрес кулланганлыгы түбәндәге факттан күренә. Галим Фулад-Тимур хан бине Тукан исемле хөкемдарның 768 (7.IX.1366 – 27.VIII.1367) елда сугылган тәңкәсе нигезендә бу шәхес турында буталмыйча, дөрес нәтиҗә ясый алган. Моннан аңлашыла ки, Мәрҗани бу акчалардагы язуларны үзе дә укыган. Әлбәттә, аның «гадел Мамай хан[ның] 763 тә (31.X.1361 – 20.X.1362) Актүбә вә Азакта [суккан] тәңкәләре бар» дигән ялгышы заманының историографик хатасын кабатлау гына дип кабул ителергә тиеш. Чынлыкта Актүбә шәһәрендә Алтын Урда акчалары сугылмаган, Мамай да үз исеменнән акча суктырмаган һәм хан да булмаган.

«Мөстәфадел-әхбар»ның беренче томы халкыбызның XVI йөзгә кадәрге тарихына багышланган, икенче томы XVI гасырдан алып XIX гасырга чаклы булган тарихыбызны яктырта.

Кызганычка каршы, «Мөстәфадел-әхбар»ны уку һәм аңлау махсус хәзерлеге булмаган укучы өчен шактый кыен. «Мөстәфадел-әхбар» татар телендә язылган булса да, текстында бик күп гарәп һәм фарсы сүзләре һәм гыйбарәләре кулланылган. Кайбер урыннарда Ш. Мәрҗани госманлы төрекчәсендә язган. Гарәп, фарсы, госманлы чыганакларыннан китерелгән зур өзекләр Мәрҗани хезмәтендә тәрҗемәсез бирелгәнгә, китапның, бигрәк тә беренче томының, теле татарча-гарәпчә-фарсыча-төрекчә килеп чыккан. Аңлашыла ки, бу хезмәт тәрҗемә ителергә тиеш.

Ә. Н. Хәйруллин тарафыннан хәзерләнгән һәм 1989 елда дөнья күргән «Мөстәфадел-әхбар»ның бүгенге татар теленә тәрҗемәсе, заманының идеологиясеннән чыгып, шактый кыскартылган. Мәсәлән, Болгар дәүләтенә багышланган өлеш тулысынча бирелсә, Алтын Урда чорына багышланган бүлек төшереп калдырылган.

70 ел буе татар тарихын тарайту, бозу һәм кимсетү белән шөгыльләнергә мәҗбүр булган тарихчыларыбыз бүген яңадан Мәрҗани салган юлга кайттылар. Бу гына да аның татар тарих фәнендә тоткан дәрәҗәсенең югарылыгын күрсәтә. Шуңа күрә әлеге әсәрнең киң катлау укучыга кайтарылуы бик мөһим. Әмма бу ихтыяҗ әлегә канәгатьләнми кала. Күптән түгел «Мөстәфадел-әхбар»ның беренче томы русчага тәрҗемә ителеп дөнья күрсә дә, аның түбән дәрәҗәдә башкарылуы фән дөньясында зур канәгатьсезлек тудырды[5]. Басма әзерләүдә тарихчылар, татар, гарәп, фарсы һәм төрек теле белгечләре катнашмаганлыктан, аның текстында шактый хаталар җибәрелгән. Мәсәлән, чыганаклардан оригинал телендә китерелгән өзекләр күпчелек очракта төшереп калдырылган, озын җөмләләр кыскартылып тәрҗемә ителгән. Тәрҗемәдә һижри еллар күрсәтелгән күп кенә даталар йә бөтенләй төшереп калдырылган, йә милади ел исәбенә дөрес күчерелмәгән. Тәрҗемәче комментарийлар бирүне дә кирәк дип тапмаган.

Ш. Мәрҗанинең Алтын Урдага биргән бәяләмәләре Р. Г. Фәхретдинов тарафыннан язылып чыкты инде[6]. Шуңа күрә, монда бу мәсьәләгә тукталып торуның кирәге юк дип уйлыйбыз. Билгеле булганча, Ш. Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар»ның беренче томы башында ук, бик мәшһүр булып киткән, татар үзатамасын яклауга багышланган гыйбарәсе урын алган. Алга таба, татар халкының нигезен тәшкил итүче халык һәм кабиләләрдән ул кыпчак, болгар һәм татарларны телгә ала, Алтын Урда чорында бу кабиләләрнең татар булып

EV_1_08.indb 181 13.05.2008 12:20:43

китүе турында яза[7]. Чыңгыз хан һәм аның уллары турында язганда, аларның «төп нәселләре татар түгел, магул» икәнлекләрен искәртә[8]. Алтын Урданың бөек дәүләт булганлыгын, бик күп җирләрне, шул исәптән рус кенәзлекләрен дә буйсындырып торганлыгы турында яза, Алтын Урдада яшәгән бөек галимнәр, мәшһүр шәхесләр турында да онытмый.

Ш. Мәрҗани, чын тарихчы буларак, Болгар дәверен дә, Алтын Урда заманын да, башка дәүләт һәм чорларны да идеаллаштырмаган. Ул илнең бөлгенлеккә төшүенең төп сәбәбен мәгърифәтнең түбәнәюендә, үзара җәнҗал, талаш-тырышларда һәм тышкы дошманнарның яуларында күргән. Гомумән әйткәндә, «Мөстәфадел-әхбар»дагы тарихи концепция бүген татар урта гасыр тарихы белән шөгыльләнүче профессиональ тарихчыларның карашлары белән тәңгәл килә.

Без, алда әйтелгәннәрне истә тотып, «Мөстәфадел-әхбар»ның 1989 елгы басмасына керми калган Алтын Урдага багышланган өлешен укучыларга тәкъдим итәбез.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Валидов Д. Очерк истории образованности и литературы татар. – Казань, 1998. – С. 61.
2. Temir A. Şehabeddin Mercani. Hayat, Şahsiyeti, Eserleri // Önsöz. Şehabeddin Mercani. Müstefadül-Ahbar fi ahvali Kazan ve Bulgar. T[illegible]ük Tas[illegible]. – Ankara, 1997. – S. 7.
3. Шунда ук. Шулай ук кара: Марджани: ученый, мыслитель, просветитель. – Казань, 1990. – 192 с.
4. Госманов М. Г. Шиһабетдин Мәрҗани һәм тарихи чыганакларны өйрәнү // Мәрҗани: тарих һәм хәзерге заман. Мәкаләләр җыентыгы. – Казан, 1998. – Б. 17.
5. Марджани Ш. Извлечение вестей о состоянии Казани и Булгара (Мустафад аль-ахбар фи ахвали Казань ва Булгар). – Казань, 2005. – Ч. I. – 255 с.
6. Фәхретдинов Р. Г. Мәрҗани — татар тарихының атасы // Мирас. – 1998. – № 8. – Б. 74-78.
7. Temir A. Şehabeddin Mercani. Hayat, Şahsiyeti, Eserleri... – S. 94.
8. Шунда ук.

Илнур Миргалиев,
тарих фәннәре кандидаты

«Аллах аларны иманга керү,
мөлк вә хакимияткә ия булу белән бүләкләсен»

Беренче төркем, ягъни Саини* патшалар турындагы бүлек

Беренчеләре аларның Җүҗи хан бин Чыңгыз хан бине Йәсүгәй бине Бортай бине Кабил бине Тумна бине Бай С.нт.р** бу буынның асылы һәм соңгысыдыр. Җүҗи хан атасыннан алдарак 627 (20.XI.1229 – 8.XI.1230)*** елны дәштә**** вафат булганнан соң, Чыңгыз хан Җүҗиның икенче улы Батуны Җүҗи олысына бәйсез хөкемдар итеп билгеләде, ул исә башкала итеп Сарай шәһәрен төзи башлады. Аны бетерү алдыннан вафат булгач, патшалык туганы Бәркә ханга бирелде. Хакимият Бәркә хан кулында булган чакта Сарай шәһәре төзелеп бетте. Чыңгыз улларыннан беренче булып ислам диненә Бәркә керде. Җүҗи олысының исеме Бату урдасы һәм Бәрриятел-Бәркә***** исеме белән танылды.

Кушаматы «Саин» булган Бату хан мөлкәт җире булган Сарай шәһәрен төзи башлады, вә шул вакыт 651 (3.III.1253 – 20.II.1254) елында вафат булды. «Тибъянун нафигун Борһанун катыйгун» тәрҗемәсенә таянып бә (б) вә әлиф (а) вә тә (т) вау (у) белән

* Саини — Бату ханның исеменә кушылып әйтелә торган сүз. Мәгънәсе — кадерле, хөрмәтле, сайланган. Монда Саини дип Бату-хан токымы күздә тотыла, ягъни Батуидлар (биредә һәм алга таба И. Миргалиев аңлатмалары).
** Сүз аңлашылмый.
*** Ш. Мәрҗани һиҗри еллар кулланган. Милади укылыш безнең тарафтан бирелде.
**** Биредә «дала» мәгънәсендә.
***** Бәркә даласы.

EV_1_08.indb 182 13.05.2008 12:20:43

Бату «чаку»* үлчәмендә Шабанкарә лөгатендә** т.р.җ*** мәгънәсендәдер. «Фату», «мату», «гаду», «каму» калыбында була. Аннан соң Мәңгү хакан аның улы Сартак ханны әтисеннән соң Сарайга хан кылды, ләкин ханлык тәхетенә утыру алдыннан ул вафат булды. Русия хөкемдары Александр бине Ярослав ән-Нифи моңа ант бирергә килде. Казан шәһәрене шушы Сартак хан төзеде дигән сүз бар.

Аннары туганы Улакчы**** хан булды, әмма моннан аз вакыттан соң вафат булды. Аннары абыйсы***** Насыйреддин әбел-Мугали Бәркә хан булды. Әбел-Мозаффар Амр ибнел-Вәрди вә Нәбакти вә башкалары Бәркә ханны Бату хан улы диләр, әмма Ибне Гарәбшаһ вә Әбел-Гази хан вә «Раузатес-Сафа» вә «Миръател-галәм» вә «Җамигат-тарих» хаклы рәвештә [аны] Җүҗи хан улы диләр. Аллаһы тәгалә бу бәндәсенең күңеленә тәүфикъ вә һидаят салып, иман белән шәрәфләндерде. Ул ислам диненә керде, аңа ияреп туганы Тукай-Тимур да мөселман булды. Асылда Бәркәнең исеме Бурка углан иде, мөселман булгач Бәркәгә алыштырылды.

Бәркә хан Иран дәүләте хөкемдары Абага хан бин Һулагуга каршы Букай исемле гаскәр башы җибәрде. Ул Дәрбәндтән үтте һәм сугышып җиңелде. Абага хан Кура елгасын кичсә дә, Бәркә ханның өч йөз мең гаскәр белән якынлашуын ишетеп кире борылды. Абага хан күперләрне җимерттерде, ике гаскәр ике тарафтан дүрт көн буе атышканнан соң Бәркә хан Тифлискә юнәлде вә юлда куланч гыйлләтенә дучар булды. «Раузатес-Сафа»да Бәркә хан турында «мөселман патшасы булган, галимнәр һәм шәехләрнең киңәше белән йөргән, — диелә. — Аннан соң Абага хан, ул тарафта биек дивар төзергә һәм чокыр казырга боерды. Капкаларны берничә монгол гаскәре сакларга калды...»****** — дидер. Җүҗи балаларыннан, бәлки бөтен татар ханнары вә Чыңгыз балаларыннан әүвәл исламга кергәннәре шушы заттыр.

«Әл-Кодури»га аңлатма язучы һәм «Әл-Кунәййә»не******* язучы Нәҗмеддин Әбер-Риҗа Мохтар бине Мәхмүд әз-Захиди ислам дине хакында бер китап язып, Рәсүлүлла салләллаһы галәйһи вә сәлләмне бәйан итеп, исемен «Рисаләи Насыйрия» куеп, Бәркә ханга бүләк итте. Бәркә хан егерме биш ел патша булып, 664 (13.X.1265 – 1.X.1266) елда эч авыруы белән авырып вафат булды вә Сарайда җирләнде. Азәрбайҗан вә Гаҗәместан патшасы булган, әти ягыннан абыйсының улы булган Һулагу хан бине Тули хан бине Чыңгыз хан өстенә гаскәр җибәреп, Аллаһының сагында булган хәлифәнең кыйссаларын таләп итеп, ничә тапкыр сугышлар кылды вә күпчелек җиңде, ә Һулагу хан җиңелде. Аннары Һулагуның улы Абага хан белән дә шундый ук хәл булды. Соңыннан Бәркәнең туганының улы Мәңгү-Тимур хан бине Тукан бине Җүҗи хан тәхеткә чыкты. Шәһри Болгарда сугылган акчада «Мәңгү-Тимур хан әл-Әгъзам зуриба һәзәд-дирһәмү фи Болгар сәнәтән 673 (7.VII.1274 – 26.VI.1275) әл-гыйззу әд-даиму вә әш-шәрәфү әл-каиму тәвәккәлә галәллаһи мөхәррәм сәнәтән 678 (14.V.1279 – 2.V.1280) хәмдүн лиллаһи лә илаһа илләллаһу вахдәһү лә шәрикә ләһү»******** гыйбарәләре язылган.

Ибнел-Вәрди әйтә: 665 (2.X.1266 – 21. IX.1267) елында татарлардан бер гаскәр Кустантинияга ирешеп, шул якларны бастылар, Рум сәлҗүкләре солтаны Кәйкәүс бине Кәйхусраф бине Кәйбкад тоткын булган кальгага барып аны азат итеп, якыннары һәм балалары белән бергә Мәңгү-Тимур хан хозурына алып килделәр. 620 (4.II.1223 – 23.I.1224) елдан бирле тоткын иде, аны Мәңгү-Тимур хан зурлап хөрмәт итте вә үз кызын бирде. 677 (25.IV.1278 –

* Бату «чаку» вәзенендә Шабанкарә лөгатендә «т.р.ж » мәгънәсендәдер, ки агач кавындыр, кабыгыннан мөрәббә үстерелгән диләр вә «Хуббу әс-сәлатыйни вә Чыңгызия»дән бер солтан исемедер, көза «Фи тибъянин нафигыйн» сәлләмәһуллаһу тәгалә (Ш. Мәржани искәрмәсе).

** Монда Мөхәммәд бине Гали бине Мөхәммәд бине Хөсәен Шабанкарәинең «Мәжма‘у’ль-ансаб» әсәре күздә тотылса кирәк.

*** Сүз аңлашылмый.

**** Чынлыкта Улакчы Сартакның улы иде.

***** Ягъни, Сартакның әтисе ягыннан туган абыйсы.

****** Бу чыганактан китерелгән өлешләр фарсыча бирелгән. Гарәпчә һәм фарсыча әсәрләрдән өзекләрне Мәржани оригинал телендә китергән. Монда безнең тәрҗемәдә бирелә.

******* «Кушаматлар».

******** «Мәңгү-Тимур хан әл-Әгъзам. Ошбу дирһәм 673 (7.VII.1274 – 26.VI.1275) елында Болгарда сугылды. 678 (14.V.1279 – 2.V.1280) елында мөхәррәмдә үзен даими көч, бөек шәрәф Аллага тапшырды. Аллаһыга хәмед, Аллаһыдан башка илаһ юк, ул бер, аның уртагы юк».

EV_1_08.indb 183 13.05.2008 12:20:43

13.V.1279) елында вафат булганчы анда торды вә Сарайда җирләнде. Кәйкәүс вафатыннан соң Мәңгү-Тимур хан, мәҗүсият йоласы белән гамәл кылып, тол калган кызын аның улы солтан Мәсгудькә бирергә теләде. Моннан соң Мәсгудь качып китеп, Рум җиренә урнашты. Аны тотып, Абага хан бине Һулагу хан хозурына китерделәр, ул аңа хөрмәт күрсәтте һәм Сивас вә Әрзәнер-Рум вә Әрзән-кан шәһәрләрен бирде вә солтанат әр-Румны аның исемендә кылды. Якынча 708 (21.VI.1308 – 10.VI.1309) елга хәтле яшәп, Византиядә сәлҗүкләрдән солтан итеп исемләнгәннәрдән соңгысы иде.

Мәңгү-Тимур хан 681 (11.IV.1282 – 31.III.1283) елында сиксән мең гаскәр белән Нукай вә Тукайны гаскәр башы кылып, Аргун хан бине Абака хан өстенә җибәреп, Аргун хан гаскәр башы Тугачар исемле кешегә Карабагда очрашып Мәңгү-Тимур хан гаскәре җиңелде. Шул елны Мәңгү-Тимур хан үзе дә вафат булды.

Аннан соң туганы Туда-Мәңгү хан бине Тукан хан булды. Сарайда сугылган акчасында: «Туда-Мәңгү хан әл-Гадел. Зуриба фи биләди Сарай сәнәтән 681 (11.IV.1282 – 31.III.1283) ситтәмият вахиди вә сәманин. Әл-гыйззәтү ли-Ллаһи вә ли-рәсүлиһи»*. — дип язылган. Әбел-Гази хан тарихында әйтәдер: «Күп золым вә гаделсезлек кыла башлады. Туктагу хан бине Мәңгү-Тимур хан аның золымыннан качып китте», — ди. Ибнел-Вәрди «Тарих»ында әйтәдер: «686 (16.II.1287 – 5.II.1288) елда татар илендә мөэминнәрдән булган Мәңгү хан бине Туган тәхетеннән төште һәм урынына туганының улы Тула-Буга хан бине Мәңгү-Тимур ханны калдырды».

«Тарихы Нәбакти»дә әйтеләдер: «Тарбу уллары Алгу һәм Тогрыл, Туклан Тулабуга уллары һәм Кунҗәк Туда-Мәңгүне диваналык аркасында тәхетеннән төшерделәр һәм үзен биш ел дәвамында уртак иттеләр, һәм Туктай бине Мәңгү-Тимур максат итеп Багизкай бине Татар бине Һардалдан ярдәм сорап, ул аны үтерде.

Аннан соң туганының улы Тулабуга хан бине Мәңгү-Тимур хан Туда-Мәңгү ханнан соң Сарай патшасы булды. Ибнел-Вәрди аны 690 (4.I.1291 – 23.XII.1291) елда Нәгбәт бине Могол бине Татар бине Җүҗи хан үтерде дидер. Вә аннан соң Туктуга бине Мәңгү-Тимур хан утырды һәм үзе белән туганнарын Берлек вә Сарайны урнаштырды дидер.

Аннары туганы Казан хан. Казан шәһәре үз исемен аңа нигез салучы Казан исемле ханнан алган дигән сүз бар. Җүҗи хан нәселеннән бу исем йөрткән өч шәхес билгеле: берсе — алда телгә алынган Казан хан бине Туган бине Җүҗи хан, икенчесе — Казан бине Баян бине Байтимур бине Туктимур бине Җүҗи хан, өченчесе — Казан бине Аячи бине Тули бине Урда бине Җүҗи хан. Шулай ук Чагатай хан улларыннан Мавәраэннәһердә Казан-Солтан хан бине Ясүр** бине Урк-Тимур бине Тугай-Тимур бин Кудгай бин Бузай Мүтүкен бин Чагатай хан бин Чыңгыз хан. Вә Тули хан бин Чыңгыз хан улларыннан Казан хан бине Аргун хан бине Абага хан бине Һулагу хан бине Тули хан. Тули хан улларыннан башта исламга кергән танылган зат шул патшадыр.

Аннары туганы Гыяседдин Туктагу хан бине Мәңгү-Тимур хан бине Туган. Әбел-Гази хан тарихында әйтәдер: Туда-Мәңгү ханнан качып китеп, берничә вакыттан соң гаскәр туплап килеп Туда-Мәңгүне җиңеп патша булды, ата вә агасы аңа киңәш кылып торды, алты ел патшалыгыннан соң Сарайда вафат булды һәм җирләнде.

Ибнел-Вәрди әйтәдер: 712 (9.V.1312 – 27.IV.1313) елда Кыпчак патшасы Токтакай утыз яшендә вафат булды, тәхеткә җиде яшьлек улы утырды. Потларга табынучы кәфер үлде, төрле милләтләрдән булган хикмәт ияләрен һәм белгечләрне ярата иде, мөселманнарга башкаларга караганда өстенлек бирә иде, һәм мөселман төркиләр яшәгән өлкәләрдә патшалык итәргә ниятләде, һәм әтисе яшендә үлде, һәм үзеннән соң улын калдырды һәм эше бетмәстән аннан соң туганының улы Үзбәк хан патша булды. Аның бик күп гаскәре бар иде. Ул һәм аның дошманнары арасында сугыш купты. Һәрбер дистәдән берне аерды, һәм шул аерылганнарның саны 250 000 атлыга җитте», — дидер.

Фәкыйрь тәрҗемәче*** уйлавынча, Туктагу ханны «потларга табынучы кяфер» дию хата

* «Туда-Мәңгү хан әл-Гадел. 681 (11.IV.1282 – 31.III.1283) елында Сарай шәһәрендә сугылды. Гыйззәт Аллага һәм аның Рәсүленә».
** Яки Бәсүр.
*** Ягъни, Ш. Мәржани үзе.

EV_1_08.indb 184 13.05.2008 12:20:43

булса кирәк. Нәбакти аны: «Банукай бин Татар бин Һардал вә Нугай бин Татар бин Буал бин Җуҗи хан ярдәм сорады, аларны үтерде, аннан соң Банукай янә җиңде» — дидер. «Раузатес-сафа» да: «703 (15.VIII.1303 – 3.VIII.1304) елда Тукай һәм Нугай арасында Саксин белән Болгар чигендә куркыныч сугыш булган. Тукай җиңгән, һәм тәхеттә булган көчле фәрман бирүчене үтергән. Ул Азәрбайҗан һәм Иран өлкәләрнең казанышларын үзенә таләп итте. Бу өлкәләрне Чыңгыз хан безгә өләште дип Казан ханга илче җибәрде, Һулагу һәм аның уллары һич сәбәпсез аны үзләренә алганнар», — диде.

Вә тагын «Раузатес-сафа» да әйтеләдер: «Илчеләрне куркан белән бергә Казан хан янына җибәрде. Хатның асылы шулдыр ки, Чыңгыз хан өләшүенчә Иран һәм Азәрбайҗан мәмләкәтләре Җуҗи хан һәм аның улларының булырга тиеш. Инде ничә еллар буе Һулагу хан һәм аның уллары бу өлкәләрнең уңышларын Ясага каршы буларак кулланалар. Газанның икенче көнне әйтәсе сүз шул булырга тиеш: бүген хакын үз мәркәзендә билгеләргә тиеш һәм өлкәләрне тапшырырга тиеш, югыйсә сугышка әзер булсын, һәм шуны белсен: Каракорум* чигеннән Дәрбәнд тирәсенә чаклы безнең җиңеп йөрүче каравылчылар куелган, ун мең чатыр корган, бауларын тарттырып, көтеп, әзер булып утыралар, калган гаскәр дә шулай эшләргә тиеш».

«Гаскәрнең күбәеп барган көчен күрсәтү өчен тары тулы кечкенә капчык алар алдында ачып тышка әйләндереп күрсәттеләр. Илчеләр хатның эчтәлегендәге дорфалыкны мөмкин чаклы матур гыйбарәләр, татлы сүзләр белән җиткерделәр. Илчеләрнең күп булудан патшаның ачуы чыкты, шундый җавап бирде: «Ул патшаның хакимияте дәвамсыз һәм аның таләпләре авыруныкы төсле, чөнки Һулагу хан дәвереннән бүгенгәчә Иран вә Азәрбайҗан безнең сугышып алган һәм киң җирләребезгә кушылган өлеше. Бүгенге таләпләрегезне исә тик кылыч кына хәл итә ала дип төшенәбез. Бүгенге низаг кылычсыз хәл ителмәс. Бу хәбәрләрегез белән бергә тары тулы капчыгы гына түгел ә берничә тавык та алып килергә иде, алар шундук чүпләп бетererләр иде», — диде. Вә Туктайның илчеләренә китәргә рөхсәт бирде. Туктай ханның 690 (4.I.1291 – 23.XII.1291) елдан 713 кәчә (28.IV.1313 – 16.IV.1314) тәңкәләре бар.

Аннары туганының улы Гыяседдин Үзбәк хан бине Тогрыл бине Мәңгү-Тимур хан тәхеткә чыкты. Татар патшаларының иң бөеге, иң хәерлесе, иң диндарыдыр. Ибнел-Вәрди әйтәдер: «Абыйсыннан** соң булган патша. Яшь, мөселман, батыр. Өлкәсенең киңлеге алты ай барасы, ләкин шәһәрләре кечкенә», — ди. Бу патша бик затлы вә акыллы вә исламны таратуда аеруча көч вә әһәмият белән вә көннәрендә татарның күпчелеге тынычлык вә иман дине исламга кереп, вә иман белән шәрәфләнеп вә диндә нык торучы булдылар. Татарлар мөселман хан гасырында исламга кереп аннан соң мөселман булмаган хан булганда күбесе иртидад итә торган булганнар.

Шуңа күрә нугай таифәсе арасында «дин Үзбәктән таралды» дип танылган сүз бар. Төрле яклардан, ерак өлкәләрдән хозурына галимнәр җыелды, мисле «Әл-Мәталигыш-шәмсия»не*** шәрех кылган зур галим Котбеддин әр-Рази вә Әхмәд бине Мәхмүд әл-Җөнди вә әс-Сәйид Җәлаледдин «Әл-Хаҗибият»не**** шәрех кылучы, вә күп халык, хәнәфи һәм шафигый галимнәре җыелды. Вә тагын Гали бине Мөхәммәд бине Диһкан әл-Бәйканди «Мифтахел-голүм»нең***** өченче бүлеген шәрех кылып 719 (22.II.1319 – 11.II.1320) елда шәгъбанда Харәземдә тәмамлап, Үзбәк ханга бүләк итте. Кереш сүзендә телгә алынгандыр. Әбел-Гази хан тарихында әйтәдер: «Туктагу хан вафатыннан соң ун өч яшендә ата-бабасының кануны белән үз-үзен тотып һәркемнең мәртәбәсенә лаек хөрмәт кылып бүләкләр бирде вә ил-олысыны исламга кертте, халык ул байлык иясе сәбәбеннән шәрәфе ислам белән мөшәррәф булдылар, аннан соң барча Җуҗи илен Үзбәк иле диделәр, та кыямәткәчә әйтеп торырлар, дады гаделнең дадын бирде вә ике мәртәбә Иран йортына Әбү Сәгыйдь хан өстенә барды, әмма ала алмый кайтты.

* Бөек Монгол империясенең башкаласы.
** Сүз әтисе ягыннан булган абыйсы турында бара.
*** «Кояшның тууы».
**** «Яшерен».
***** «Белемнең ачкычы».

EV_1_08.indb 185 13.05.2008 12:20:43

Әбү Габдуллаһ бине Баттута «Төхфәтен-назар»* китабында әйтәдер: «Синоптан Кырым мәмләкәтенә чыктым. Ул вакыт анда солтан Мөхәммәд Үзбәк хан тарафыннан Теләк Тимур исемле әмир хаким иде. Ул миңа имамы Сәгъдеддин белән бер ат җибәрде. Ул мәмләкәтнең шәехе Задә әл-Хорасани иде. Аңа юлыктым, казый әгъзамнары Шәмседдин әс-Саили әл-Хәнәфи вә казый әш-Шафигый Хызыр вә "Мәлик Насыйр" мәчетендә хатыйплары Әбү Бәкер вә хәким Мозаффареддин вә шәех Мозаффареддин әл-Фәкыйһ вә әмир Теләк-Тимургә кергәндә ул авырый иде, безгә ихсан кылды, Сарай шәһәренә солтан Мөхәммәд Үзбәк хан хәзрәте хозурына барырга максатым иде, юлдаш булып туганы Гайсә вә Котлы-Дәмир вә Сарубәк вә имам Сәгъдеддин вә хатыйп Әбү Бәкер вә казый Шәмседдин вә фәкыйһ Шәрәфеддин Муса вә Галәэддин әл-Могаррәф белән бергә сәфәр кылдык. Ул Могаррәфнең вазифасы әмир алдында мәҗлесендә бер казый йә фәкыйһ йә күренекле кеше килсә, аякка калкып көчле тавыш белән әйтәдер: "Бисмиллаһи, безнең сәйедемез мәүламыз казыел-козат вәл-хөккям мөбәййәнел-фәтава вәл-әхкям, бисмиллаһи", яки "Бисмилләһи, сәййидена Фәләнеддин, бисмиллаһи", дию. Алда булган кеше аның керүенә торырга һәм мәҗлестән урын бирергә хәзерләнәдер».

Ибне Хәлдун әйтәдер: «Җүҗи хан уллары, туганнарының уллары, Һулагу хан уллары арасында һәр вакытта фетнәләр вә сугышлар вә Җүҗи уллларының Мисырда булган төрки патшаларына дуслыклары вә һәр вакытта илче җибәреп бүләкләшмәкләре бар иде». 713 (28.IV.1313 – 16.IV.1314) елда Үзбәк хан патша булгач тәбригенә Мисыр патшаларыннан илче килеп дуслык күп булды, Мисыр патшасы әл-Мәликен-Насыйрга Тугачи бине Һинду бине Бәкер бине Җүҗи хан кызы Толынбашны Үзбәк хан имамы Борһанеддин вә татар әмирләреннән бер җәмәгать белән Мисырга җибәреп, казыйлар вә фәкыйһлар вә илнең бөекләре хозурында 720 (12.II.1320 – 30.I.1321) елда никахлары теркәлде вә бүген ике вәкил арасында теркәлеп бик зур шөһрәтле көн булды. Үзбәк хан белән Иран патшасы солтан Әбү Сәгыйдь бине Ходабәндә арасында дошманлык дәвам итте. Әбү Сәгыйдькә Үзбәк хан тарафыннан әмир Чупан җиңүе сәбәбеннән нәфрәт бар иде, шул вакытта Үзбәк хан Хорасан өлкәсенең күп шәһәрләрен кулына алды, Мәлик Насыйрдан Әбү Сәгыйдь вә Чупанга каршы берләшү һәм ярдәмләшүне таләп итеп, Мәлик Насыйр кабул итсә дә, Мисырга Әбү Сәгыйдь тарафыннан Итмеш әл-Мөхәммәди килеп, 722 (20.I.1322 – 9.I.1323) елда солых вә ислах рәвешендә ислам кушканын үтәүгә вә дин дошманнары белән җиһад кылырга дип берләштеләр. Бу хәбәр Үзбәк ханга барып җиткәч, Мисыр илчеләренә бик каты сүзләр әйтеп, Мәлик Насыйрны шелтәләде. Мәлик Насыйр: «Алар безне ислам йолаларын үтәүгә, бердәмлеккә өндәделәр, бу исә рөхсәт ителгән әйберләргә каршы түгел вә шәригать буенча тыелган», дип акланды. Моннан соң Үзбәк хан вә Әбү Сәгыйдь хан ризалашып солых кылдылар. [Үзбәк хан] Әбү Сәгыйдь ханга алган Хорасан шәһәрләрен кире кайтарып бирде. 741 (27.VI.1340 – 16.VI.1341) елны Сарай шәһәрендә вафат булды. 718 (5.III.1318 – 21.II.1319) елда Дәрбәнд юлы белән Азәрбайҗанга вә икенче тапкыр 736 (21.VIII.1335 – 9.VIII.1336) елда Иранга сәфәр кылды. 718 елда Русия хөкемдары Юрий бине Данил ант һәм тәбрик өчен Үзбәк хан хозурына килде.

Аннары улы Төнбәк хан булды, әмма ханлык вакыты аз булса кирәк. Аннары туганы әс-солтан Җәлаледдин Әбел-Мозаффар Мәхмүд Җанибәк хан туганыннан соң 743 (6.VI.1342 – 25.V.1343) елда Сарайда патша булды, Москва хөкемдары Семен бине Иван вә Митра ант вә тәбриккә килделәр. Зур галим Сәгыйдеддин әт-Тәфтазани кыскача шәрехне тасниф итеп Җанибәк ханга бүләк итте. Кайбер нөсхәләрендә «бик диндар, яхшы, гадел, матур йөзле һәм яхшылык теләүче сыйфатка ия иде», дип исеме телгә алына. Казый Мөхйиддин әл-Бәрдәгый хосусан Сарай шәһәренә килеп, мәчеттә патша Әшрәф бине Тимурташ бине Чупан** золымын тәфсилләп бәйан кылып шикаять итеп, анда килгән җәмәгатьне бөтенләй елатты. Аннан соң Җанибәк хан бөек гаскәр белән Азәрбайҗан мәмләкәтенә хәрәкәт итте, Әшрәфне җиңеп һәм үтереп, мәмләкәтен алды, вә халыкка золым кылып аннан тупланган бөтен

* «Күзәтүче бүләге».
** Чупан патша түгел, бу вакытта ильханнар дәүләте таркалган иде инде. Чупан үз кулына Азәрбайҗанны төшергән вә идарә итә иде.

EV_1_08.indb 186 13.05.2008 12:20:44

хәзинәләрен вә Әшрәфнең улы Тимурташны Сарай шәһәренә алып кайтты. Бу турыда ошбу фарсы бәетен әйттеләр:

Дани ки чи кәрд Әшрәф хәр
У мазләмә бурд Җанибәк зар.[*]

Тәбриздә илле мең гаскәр белән улы Бәрдибәк ханны калдырды. 758 (25.XII.1336 – 13.XII.1337) елда Сарай шәһәрендә вафат булды. «Раузатес-сафа»да әйтеләдер: «Әшрәф бине Тимурташ патша өлкәне нык кулына алды вә чиксез золым кылды. Вә казый Мөхйиддин әл-Бәрдәгый бу золымның күплегеннән башкалар шикелле Сарайга китте һәм шул өлкәдә вәгазьләр белән мәшгуль булды һәм аны Тәфтазани дигән зур галимнең кыскача шәрех иткән «Мәгани һәм бәйан фәне»н[**] язган гадел һәм мәрхүм Җанибәк хан патшаның шәриф исеменнән кылды, вәгазьгә хан да килде һәм казый җәнаблары аны Әшрәф белән сугышуга этәрде, һәм ул аны җиңде, казыйның ишарәсе белән аны үтерделәр, аның башын Тәбризгә алып бардылар, һәм «Мурагыйан» мәчетенең ишегенә элделәр, вә шөкер сәждәләрен урынына җиткерделәр, вәгъдәләрен үтәделәр. Патша ике мең атлы гаскәр белән Тәбризгә килде, дәүләт өендә кунды, икенче көнне «Галишаһ» мәчетендә җәмәгатькә намаз кылдырды, аның гаскәрләре юл белән елгалар арасында урнашты, һичбер кешегә яран булмады, рәгыйять ханәсенә атлап керә алмас иделәр. Патша аның җанын теләде, вә улы Бәрдибәкне илле мең атлы гаскәр белән Тәбриздә калдырды, Сарай шәһәренә кайтты, берничә көннән соң Җанибәк урдасыннан патша бик каты авырый дигән хәбәр килде. Шулай итеп, Бәрдибәк ашыга-ашыга анда киткәч, Ахичук аның киткәне турында хәбәр алды вә күпсанлы төркеме белән Тәбризгә килде вә Әшрәф патша әмерендә булганнар аның хезмәтенә керделәр, вә хөкүмәт дәрәҗәсенә җайлашты, вә золым итү рәвешендә адым-адым Әшрәф патшаның артыннан эшен дәвам итте».

Әбел-Гази хан тарихында әйтәдер: «Казый Мөхйиддин Җанибәк ханга әйтте: «Әгәр барып Әшрәфтән безнең гаделлегебезне алмасаң, кыяmәт көнендә безнең кулыбыз синең итәгеңдә», — дип. Бу сүз ханга тәэсир кылып, Әшрәфне тар-мар итеп мәмләкәтене кулына алып, Әшрәфнең дүрт йөз табух[***] лал вә асыл ташлар бар иде, тәмамын гаскәренә өләшеп бирде, җиңү белән йортына кайтты, заты шәрифендә бер авыру пәйда булып инде озакка киткәч, мин бу авырудан котылмасмын, дип, улы Бәрдибәкне үз урынына билгеләп куеп, Азәрбайҗаннан дәгъвәт итте вә күп үгет-нәсыйхәтләр әйтте. Бәрдибәк килгәнче Хак рәхмәтенә китеп, Сарайда җирләнде. 17 ел патшалык кылды. Аннары улы Бәрдибәк хан атасының вафатыннан соң Сарай шәһәренә кайтты. Өч көн матәмнән соң бөтен шаһзадәләр вә әмирләр Бәрдибәкне хан күтәрделәр.

Әбел-Гази хан әйтәдер: «Бәрдибәк хан гаҗәп залим табигатьле, бозык вә начар ниятле кеше иде. Агай-эне вә карендәш-ыругны куймады, үтерде, ахыр чиктә патшалыгы ике елга җитмәде, 762 (11.XI.1360 – 30.X.1361) елда вафат булды. Моннан соң Саин хан улларыннан патша булырга насыйп булмады, үзбәк халкы эчендә «Бәрдибәк тә киселде», — дигән сүз мәшһүрдер.

760 (3.XII.1358 – 22.XI.1359) елда Русия таифәсе Болгар мәмләкәтеннән Жукутыйн кальгасен алдылар. Шул турыда Болгар әмире ханга белдереп, Русия хөкемдары Дмитрий бине Кастантыйн вә туганы хан илчесе хозурына чакырылып мөрафәга булып угрыларны табып биреп кенә җәзадан котылдылар. Аннары улы Кульна хан яшь сабый иде, алты ай патшалык исемен күтәрде. Сарай вә башка җирләрдә сугылган кайбер дирһәмнәре бар, 761 (23.XI.1359 – 10.XI.1360) елда сугылган. Аннары әтисе ягыннан булган абыйсы Нәүрүзбәк хан бин Җанибәк хан. Кульна ханны үтереп бер елдан артыграк патша булды, 60, 61, 62 нче еллардагы тәңкәләре бар. Әүвәлдә Җаек елгасының көнчыгыш тарафында иде, Җанибәк улы дип алдап Сарайга килеп хан булды.

[*] Әшрәф дигән ишәкнең ни кылганын бел, ул золымны бетерде Алтын Җанибәк.
[**] Риторика.
[***] Сүз аңлашылмый.

EV_1_08.indb 187 13.05.2008 12:20:44

Гасырында Русия хөкемдарлары хәзер татар арасына каршылыклык төште, дәүләтләре зәгыйфьләнде дип бераз баш күтәреп татар хөкүмәтеннән чыкмак һәвәсенә төштеләр вә килеп теләкләрен белдерделәр. Моны (Нәүрүзбәкне) Хызыр хан үтерде. Аннары аның туганы Килдебәк хан булды. Алтмыш ике вә алтмыш елларында Сарайда сугылган тәңкәләре бар, бу да Нәүрүзбәк хан шикелле ялганчык, хакыйкатьтә Җанибәк улы түгел диләр. Ахыр чиктә аз вакыттан соң Сарай шәһәрендә үтерелде. Бату хан улларыннан дәүләт китеп гайреләр җитәкчелек итте.

Бәгъзы җыентыкларда Казан ханнан соң аның туган абыйсының улы Кунҗәк бине Тарбу бине Тукан, аннары Алгу бине Мәңгү-Тимур хан, аннары туганы Тугрул хан дип зикер ителә. Бәлки алар Туда-Мәңгү хан гасырында уртак булып һәм бер-берсенең эшенә керешкәннәрдер. Ибнел-Вәрди әйтәдер: 700 (24.XII.1291 – 11.XII.1292) елда Җәкә үз туганы Тәкә бине Бугнәне үтерде һәм аның белән Тайфур дигән урынбасары арасында сугыш булды. Тайфур җиңде, аннары Туктагага сыенды вә Җәкә вакыт суздыру өчен Улакка качты, Улакның патшасы моны алдады, Тарбу дигән кальгага алды, аннары үтерде, башын хуҗасына җибәрде, һәм Бугнәнең мәмләкәте Туктаганыкына әверелде. 709 (11.VI.1309 – 30.V.1310) елда Байан бине Кайчы туганы Кәтләкнең мәмләкәтен җиңде вә моннан соң Кәтләкнең үлүе булды, улы Каштимер сыенды, абыйсы Байан аны куды, әтисенең мөлкәтен алды һәм Монгатый бине Кайчы дигән туганын үтерде.

Болар кемнәр булмак кирәк, Ак Урда яки Күк Урда хөкемдарлары түгел микән?

Җүҗинең Шәйбани һәм башка токым оныкларыннан чыккан төрле патшалар турындагы фасыл

Саин нәселе киселгәннән соң Җүҗи ханның бишенче улы Шәйбан бине Җүҗи хан улларыннан Ак Урда ханнары нәселеннән Хызыр хан бине Ибраһим бине Фулад бине Миңтимур бине Бадакол бине Җүҗи-Бука бине Баһадир хан бине Шәйбан хан бине Җүҗи хан Нәүрүз бәк ханны үтерүе белән 760 (3.XII.1358 – 22.XI.1359) елдан 762 (11.XI.1360 – 30.X.1361) елгача бөтен Җүҗи олысына патша булды. Болгар вә Сарайда сугылган тәңкәләре күп табыла. Аннары аның улы Тимур-Хуҗа хан булды. Атасын үтереп 762 елда биш җомга кадәр патша булды.

Бу вакыйга «Әтисен үтергән патшалыкка лаек булмас, әгәр лаек була дисәң, алты айдан артык тормас» дигән бәеттә чагылыш тапты. Мамай мирзаны җиңеп, әсир итеп, Сарай шәһәреннән чыгарып үтерделәр. Аннары Урда-Мәлик хан булды, 762 елда суккан тәңкәләре бар, Сарай вә Харәзем вә Гөлестанда. Аннары гадел Мамай хан булды, 763 (31.X.1361 – 20.X.1362) елда Актүбә вә Азакта суккан тәңкәләре бар. Аннары Мөрид хан бине Хызыр хан, 763 елда суккан тәңкәләре бар. Аннары Мир-Фулад хан, 763-764 (21.X.1362 – 9.X.1363) елларда. Аннары Фулад-Хуҗа хан, 765 (10.X.1363 – 27. IX.1364) елда. Аннары Җанибәк хан, 767 (18.IX.1365 – 6.IX.1366) елда вафаттыр. Аннары, 766 (28.IX.1364 – 17.IX.1365) елдан 772 (26.VII.1370 – 14.VII.1371) елга кадәр, Газиз-Шәех хан. Аннары Фулад-Тимур хан бине Тукан. 768 (7.IX.1366 – 27.VIII.1367) елда сугылган тәңкәсе бар, бер тарафында «Мәрхүм Җанибәк хан» дип язылган. Аннары Тулунбәк хан. Мамай мирза туганының улыдыр, 773 (15.VII.1371 – 2.VII.1372) елларда тәңкәсе бар. Аннары Гыяседдин Бүләк хан. Мамай мирза вәзире иде, 770 (16.VIII.1368 – 4.VIII.1369) – 771 (5.VIII.1369 – 25.VII.1370) елларда 787 (12.XII.1385 – 1.XII.1386) кадәр Сарайда вә Хаҗитархан, Харәзем, Урда вә Мажарда сугылган тәңкәләре бар.

Бүләк хан гасырында Мәскәү хөкемдары Дмитрий бине Иван Донской 780 (30.IV.1378 – 18.IV.1379) елда бөтен Русия хөкемдарлары белән берләшеп зур гаскәр җыеп, Дон елгасы буенда зур сугыш кылып, татар гаскәрене сындырды. Бүләк ханның хуҗалык буенча җаваплы кешесе вә җиңүче Мамай мирза ошбу бәрелештә сугыш мәйданыннан качып китеп, Кырымда һәлак булган. Бу заманнан соң Русия хөкемдарлары ислам хөкүмәтеннән чыкты. Туктамыш хан гасырында тагын аларны кайтарып итәгать астына кертте.

Аннары Алыбхан Хуҗа хан, 775 (23.VI.1373 – 11.VI.1374) тә. Аннары Чиркәсбәк хан,

EV_1_08.indb 188 13.05.2008 12:20:44

776 (12.VI.1374 – 1.VI.1375) елда. Аннары Гыяседдин Агабәк хан, 777 (2.VI.1375 – 20.V.1376) дә . Аннан соң Базарчы хан, 779 (10.V.1377 – 29.IV.1378) ел тирәсендә. Ләкин бу ханнарның һәммәсе Җүҗи олысының бөтен җиренә хан булмаган, бәгъзысы бер ягына мәлик вә бәгъзысы мөлкәт өчен үзара низаглар белән гасабият хасил итеп, акча суккан булганнар.

Бу ханнар белән тагын берничә хан бу мәмләкәттә булган татар ханнарыннан саналган булса да, бәгъзылары Болгар әмирләре җөмләсеннән, бәгъзысы Ак Урда, вә бәгъзысы Күк Урда ханнары, вә бәгъзысы бөтенләй бу мәмләкәт ханнарыннан түгел, алар да биредә әйтелергә мөнасип күрелде: мәсәлән, солтан Мөхәммәд, әмир Хәсән вә әмир Габдулла — Болгар әмирләреннән. Вә Сәйид Ракыйм вә башкалары Тимур хан бине Исан-Буга хан вә улы Ильяс-Хуҗа ханны Дәште Кыпчак ханнарыннан исәпли иделәр. [Хәлбуки,] алар Чагатай хан улларыннан Кашгар вә Мавәраэннәһер ханнарыдыр.

Туглук-Тимур* хан Мавәраэннәһердә булган ихтиляльгә бинаән 762 (11.XI.1360 – 30.X.1361) елда Мавәраэннәһергә килеп, ул якларны кулга алып, улы Ильяс-Хуҗаны Сәмәркандта куеп, Тимурны аның хезмәтендә кылды. 764 (21.X.1362 – 9.X.1363) елда вафат булганнан соң Аксак Тимер Ильяс-Хуҗа ханны мәкерле рәвештә үтереп ул якларны кулына алды. Вә Мөхәммәд Риза әфәнде «Сәбгы Сәййар»да Казан хан бине Аргун ханны вә абыйсының улы Әбү Сәгыйдь ханны вә Каганбәк хан вә улы Мәхмүд-Хуҗа хан вә Әбел-Хәер ханнарны Дәште Кыпчак ханнарыннан исәплидер. Бу сүз дә хаталы. Казан хан вә Әбу Сәгыйдь хан һәр икесе Иран патшалары, Сарай, Болгар вә башка кыпчак шәһәрләренә катнашы юк, бәлки [алар] Туктагу хан вә Үзбәк ханнарның Иран шәһәрләренә һөҗүм кылмакларыннан хәвефтә торыр иделәр**.

Каганбәк вә улы вә Әбел-Хәер ханнар Ак Урда хөкемдарларыдыр. Гатауллаһ бине Яхъя Нугайзадә әфәнде «Хадаикыл-хакаикъ фи зәйлиш-шикак»*** та әйтәдер: «...тугыз йөз җитмеш ел башларында Кафа бәкләр бәгесе Касым пашага бер микъдар капы кулы кушылып Кырым ханы Мөхәммәд Кәрәй**** хан белән Казан дигән җирдә дәрья ягына корылган Әждәрһа***** кальгасенең якынында, ягъни Хәзәр диңгезе ярында, Кара диңгезгә аккан бөек елганың кырыеннан якынча ике миль микъдары казылса, ике дәрья багланып, сәфинәләр белән ул мәмләкәтләрне буйсындырып, җиһанны яулап алган Бөек Искәндәр кеби дәрья-изолмәткә кадәр ислам нуры белән нурландыру мөмкинлеге мәгълүм, Һомаюн патшасы ул имеш.

Чыңгыз хан улларыннан булган солтан Мәхмүд Газан хан гасырында, ислам динен кабул иткән татар таифәсеннән күп санлы бер җәмәгать ул якларга яу белән барып, ул җирләрне ватан иткән. «Казан татары» Газаннан икәне хата имеш. Газиләр Газан гаскәре һәр вакыт ул якларга гизәр итмәклә, аларның ярдәме белән кяферләр якларын буйсындыру көче бар иде имеш. Газаннар дәүләтенең бетүеннән соң ул тарафтан килеп, сугыш походлары бетеп, Москоб кяферләренә буйсынып калган. Әлеге халәт Сәлим хан****** заманында ниязнамаләре тыныч җиһан капуларына******* килеп, ишарә ителгән урын казылып, ике дәрья дулкыннарының берләшүе белән хасыйл булганда Искәндәранә җиһангирлек мөмкин дигән диюләре белән мәшгуль булдылар. Ләкин Мөхәммәд Гәрәй Бәдрай бу хосуста мәкерлек итеп Госмани мәмләкәтләренең чикләре үз өлкәсенең артында сузылса, ирекле зур

* Кутлук-Тимур булса кирәк.
** Чыңгыз хан улы Чагатай хан улларыннан Юныс хан бине Увәес хан бине Шергали бине Мөхәммәд ханның заманында туганы Исан Бога хан аны әсир итеп Сәмәркандта булган мирза Улугбәккә җибәрделәр, ул Хорасанга атасы Шаһрух мирзага җибәрде, ул аны Гыйрак тарафына җибәрде, гыйлемнәрне тәхсыйль иткәннән соң Тимур улларыннан солтан Әбү Сәгыйдь мирза Карабагъ сәфәрен ниятләгәндә хәзерлек белән гаскәр вә патша әсбабына булышып, Моголистан тарафында туганы Исан Буга ханны яклау өчен шунда хан итеп куйды, вә ләкин шарт итте: без бәйсез һәм мотлак ихтыярлы патша Аксак Тимер уллары безнең гамил гамәштәләремез дип фәхр вә дәгъва итмәслекне, нитәкем бу заманга кадәр Тимур вә Чыңгыз улларыннан бер шәхесне патша вә хан исемендә кылып хөтбә вә акчаны алар исемендә итеп, алар патша монлар анлар тарафыннан наип вә гамәштә исемендә булыр иделәр. Бу дәстүрне ошбу вакыйгада солтан Әбү Сәгыйдь мирза бетерде, Аллаһының сәламе булсын (Ш. Мәржани искәрмәсе).
*** «Низагтан соң хакыйкатьләр бакчасы».
**** Гәрәй.
***** Әстерхан.
****** Госманлы солтаны.
******* Госманлы дәүләте капкаларына, сараена.

EV_1_08.indb 189 13.05.2008 12:20:44

юл ябык булып химая астында булган Мәмләкәте Мәхрүсә* эчендә калмак, ягъни милек сәхифәсе кәгазьләргә кушылу кирәк дип ислам гаскәре сахраи дигән бер сусыз чүлгә төшеп сусызлыктан көчсез вә ташланган хәлгә әйләнмеш иде. Ничә көннәр бер тамчы су булмыйча иртәнге яфрак-үләннәр өстендәге чык тамчыларын җыеп телләрен сулаталар иде имеш. Гаскәрнең бары тик яртысы гына котылды, сау-сәламәт кайтты. Мөхәммәд Гәрәй бу начарлыкның җәзасын Дәүләти Мурадиядә** күреп, ислам патшасының буйсындыруы белән буйсынган вә үлем белән җәзалау булды».

Казан исеме хосусында әйткән сүзе хакыйкатьтән бик ерак. Татарның Газан хан гасырында буйсынмау шарты белән ислам диненә керүчеләр Иран мәмләкәтендә Илханилар хөкеме астында булганнарыдыр. Бу өлкәбездә булган татар таифәсе Газан ханның олуг бабасы Һулагу хан заманында Бәркә ханга ияреп мөселман булган иделәр. Илханнар дәүләте патшалары бу мәмләкәткә яу кылу торып торсын, Бәркә хан, Мәңгү-Тимур хан, Туктагу хан, Үзбәк хан вә Җаныбәк ханнарның орышлары белән тар-мар ителгән, җиңелгән вә зарар күргән иделәр. Болгар патшалары вә Җүҗи хан олысында булган татар ханнары үзләре күп газават вә җиһад вазифасын яхшы гына башкарулары белән «Мөмтаз әл-Коръән»*** иделәр. Мондый адландыру рәвешен алардан алса дөреслеккә каршы булса да бу кадәр мөнәсәбәтсез булмас иде. Аллаһы дөресен белер.

Русхани**** патшалар турында фасыл

Русхан улларыннан күп затлар Сарайда хан булганлыкларыннан бу фасыл язылырга мөнасип күрелде. Аларның беренчесе Русхан бине Бадакол бине Туккол-Хуҗа бине Көнҗәк бине Сариҗә бине Үз-Тимур бине Тукай-Тимур бине Җүҗи хан нәсәбе Әбел-Гази хан белән бәйан кылды. «Сәбгы сәййар»дән***** тагын шулай аңлашыла. Әмма бәгъзыләр Русхан бине Җимтай****** бине Әбисан бине Сашыйбуга бине Баян бине Күбенче бине Сартак бине Урда бине Җүҗи хан дидер. Дөресен Аллаһы белер, үкенәсем килмидер, ул да болай гына әйтелгән сүз булса кирәк, Ак Урда хакиме иде. 763 (31.X.1361 – 20.X.1362) елдан 781 (19.IV.1379 – 6.IV.1380) елга кадәр бөтен олыска хан булып торган.

Аннары улы Туктагу хан булды. Аннары туганы Тимур-Мәлик хан булды. Аннан соң туганы Куержык хан, 797 (27.X.1394 – 15.X.1395) елдан 799 (5.X.1396 – 23.IX.1397) елга кадәр, вә шул елны Русия хөкемдары Василий бине Дмитрий Казанга керде, Туктамыш ханнан соң булган заман эчендә. Аннары абыйсының улы Тимур-Котлыг хан бине Тимур-Мәлик хан. Аннары туганы Бикбулат хан 797 елдан 802 (3.IX.1399 – 21.VIII.1400) елгача, вә шул елны вафат булды.

Татар теле, уйгыр каләме белән язган бер ярлыгы турында язарга мөнасип күрелде:

«Тимур-Котлыг сүзем.

Уң кул, сул кулның угланнарына аңлату. Идегү башлык, мең, йөз, ун бәкләренә. Ике эчке кәнтләргә, казый — мөфтиләргә, мөшаих суфиларга, диван битикчеләргә, тамгачы-тартакчыларга, йорт эшләнче, юллар ачучыларга, букавыл-туктауларга, ямчы-шусунчылар, кошчы-барсычыларга, кәмәче-күпер кичиләргә, базарда торганнарга, бу ярлык тота торган Мөхәммәднең үябкәгә******* аталарыны борынгы кичкән Саен хан чагындан бире бер ярлык раст тарханлык юсыны җаерып атасы Хажи Бәйрам Хуҗаны безнең хан агаларыбыз сөюрган тархан кылган җиргә син аңлата үтенде ирсә үтелен юп күреп Мөхәммәд безнең сөюрган булып, тархан булып торсын дигәнебез, бу көннән Йәмкәр вә Кырым берлә кырык җиренең тарханы Судат атлык кәнденең янында борынгы заманнан бирле мөтәхаттыр тархан булган ундинчы кыласы белә мәшһүр булган кыласы шәркабәлә юсуны җаир сулары

* Аллаһы тарафыннан сакланган мәмләкәт, ягъни Госманлы дәүләте.
** Госманлы дәүләтендә.
*** Коръән батырлары.
**** Сүз Ырыс хан турында бара.
***** «Җиде планета».
****** Чимтай.
******* В. В. Радлов «өбәгә» дип укыган һәм «предки» дип тәржемә иткән (кара: Радлов В. Ярлыки Токтамыша и Темир-Кутлуга // Записки восточного отделения Императорского русского археологического общества. – 1888. – Т. 3. – С. 21).

EV_1_08.indb 190 13.05.2008 12:20:44

белән Мөхәммәднең угланнары Инки хаҗи Мөхәммәд вә Мәхмүдне азат вә тархан булсын, боларның җир-сулары, баг-багчалары, хаммам-тегермәннәргә, тәсаррыф кыла торган җирләргә борындан калган асадларга бәсә колларга сабанчы-уртакчыларга кем ирсә күч уга тәкирмәсүн, юлсыз җирдәгеләрне тартып алмасыннар, болар тамгасы иңинчи үскү булгурды амбар малы, идәр хакы, табанлык кысмәт кубур ясагы, калак, мүсәммә, салыг, буруч, харәҗ алмасыннар, барыр-килере дә, керер-чыгары да Кырымдагы бара каю матурлек ирсә алуры да сатары да тамга-тырнак алмасын, тархан-табанлык юл хакы карауллык теләмәсеннәр, утыр-коралларын аулак тотмасын, кунак төшермәсеннәр, сул гулуфә теләмәсен, каю матурлык, зәхмәт вә михнәт вә гаваризатлардин мөсәввән вә мәхрус булсыннар, инҗ туруб тыныч лык белә шам вә сәбах әүкате шәрифләре дә бергә безнең оруг-оругумуска алкыш итә торсын дип торырга алтун нишанлык ярлык бирелде.

Тарих 800 (24.IX.1397 – 12.IX.1398) дә, барс елы, шәгъбан аеның 6 нчы көнендә.

Үз суының кәнарында, Мучуранда ирердә бителде»*.

Аннары аның туганы Шадибәк хан булды, 803 (22.VIII.1400 – 10.VIII.1401) елдан 810 (8.VI.1407 – 26.V.1408) елга чаклы Болгарда вә башка җирләрдә. Аннары туганының улы Фулад-Тимур хан бине Тимур-Котлыг хан, 810 нчы елдан 814 (25.IV.1411 – 12.IV.1412) елга кадәр Болгарда сугылган тәңкәләре бар, вә 810 нчы елда Кырымда иде. Аннары аның туганы Тимур хан 813 (6.V.1410 – 24.IV.1411) елдан 815 (13.IV.1412 – 2.IV.1413) елгача, Болгарда сугылган күп кенә тәңкәләре бар, 816 (3.IV.1413 – 22.III.1414) елда вафат булды.

Куержык хан вә аннан соң Рус хан улларыннан булган ханнар Туктамыш хан заман беткәннән соң Идегү мирза вә уллары ярдәме белән тәхеткә утырып, хөтбә вә акча исемнәрендә булып, дәүләт эшләре мирзалар кулында булуына разый була иделәр. Тимур хан, үз чиратында, Идегү мирзага буйсынмыйча: «Мин итәгатьле сарык түгел, ничек итәгатьле булыйм, бау белән тартылып баручы үгез булыйм» — диде. Араларында фетнә вә низаг кубып, сугышлар булды. Икесе дә хәрап булды. Тимур хан өлфәт батырлык вә күәт вә нәзек аңлаучан вә гыйлем белән куандырылган булуына күрсәтә торган хәлләре вә фигыльләре бар иде. Идегү мирзага ихтыяр тезгеннәрен бирмәгәнлегеннән вә улларының матур исемнәреннән файдаланганы аңлашыладыр. Аннары әтисенең абыйсының улы Борак хан бин Куерчык хан казакъ ханнарының бабасыдыр. Аннары аның улы Дәрвиш хан. Аннан соң улы Чәкрә хан, 817 (23.III.1414 – 12.III.1415) елда шәһри Болгар, Олуг Урда вә Хаҗитарханда сугылган тәңкәләре бар.

Аннары бабасының абыйсының оныгы Мөхәммәд хан бине Тимур хан бине Тимур-Котлык хан әл-Кәбир. Олуг Мөхәммәд хан исеме белән танылгандыр. 822 (18.II.1419 – 16.I.1420) елда Сарайда патша булып Саини тәхетендә утырды, вә 839 (27.VII.1435 – 15.VII.1436) елдан соң Сарайдан куылган гасырында 835 (9.IX.1431 – 27.VIII.1432) елда Русия хөкемдары Василий бине Дмитрий вафат булгач, улы Василий кече булуы сәбәпле абыйсы Юрий бине Дмитрий үзе хөкемдар булырга ниятләп, низаглашып һәр икесе Сарайга Олуг Мөхәммәд хозурына килгәннәр, вә риваять буенча урынына улы Дмитрий тәхетнең варисы булмак кирәк ысуллары булса да, Кайсари Руми суләләсеннән булган Василий София улын Византия тарафдарлары дәгъвасы белән зарури рәвештә Дмитрий хөкемдарлыгы кире кагылды вә Василий максатына иреште. Мөхәммәд хан әл-Кәбир Василийны хөкемдар кылып үзеннән илче кушып, ул Мәскәүгә килеп ханның бу хосустагы карарын укып Василийны Мәскәү тәхетенә утыртты. Русия халкы Урда ханнарына һәрвакыт хәражларны вакытында тапшырачакларын вәгъдә итеп теркәп куйдылар.

Аннары аның туганы — Мөхәммәд хан әс-Сагыйр исеме белән танылгандыр. Ак Урда хөкемдары Ядкәр хан бин Тимур-Шәех хан әш-Шәйбани ярдәме белән патшаның йорты Сарайга һөҗүм кылып, агасы Мөхәммәд хан әл-Кәбирне җиңеп, аннары 839 (27.VII.1435 – 15.VII.1436) елда Сарайдан куып 877 (8.VI.1472 – 28.V.1473) елгача Сарайда үзе хан булды.

* Бу ярлык оригинал телендә бирелә (чагыштырыр өчен кара: Радлов В. Ярлыки Токтамыша и Темир-Кутлуга // Записки восточного отделения Императорского русского археологического общества. – 1888. – Т. 3. – С. 1-40; Тарханные ярлыки Тохтамыша, Тимур-Кутлука и Саадет-Гирея с введением, переписью, переводом и примечаниями, изданные И. Березиным. – Казань, 1851. – 56 с.).

EV_1_08.indb 191 13.05.2008 12:20:44

Аннары улы кече Әхмәд хан булды. Аксак Тимер улларыннан Хорасан патшасы Солтан Хөсәен мирза бине Байкураның үзенең кызы Бикәй Бикәмне кияүгә биреп 9 улы булган. 877 нче елда Русия мәмләкәтенә барып әл-Яксин* кальгасенә һөҗүм кылса да, бер тарафтан руслар күп гаскәр белән каршы килеп, вә бер тарафтан Хан Кирмән хөкемдары** Даниял бине Касыйм хан, вә бер тарафтан туганы Мортаза килгәненнән хәбәр алып, Мортаза вә Данияларның патша йорты Сарайга һөҗүм кылмакларыннан куркып кире кайтты.

Аннары улы Сәйид-Әхмәд хан туганнарының низаглашуларыннан тыныч була алмады. Әхмәд ханны Себер ханы Апак хан бин Мәхмүд хан 889 (30.I.1484 – 17.I.1485) елда һөҗүм кылып үтерде.

Аннары улы Сәйид-Мөхәммәд хан булды. Аннан соң абыйсы шейх Әхмәд хан бине Кечек Әхмәд хан. Бу хан шәһри Сарайда булган татар ханнарының соңгысыдыр. Аннан соң Сарайда булган татар дәүләте бөтенләй таралып, патша йортлары бөтенләй харап булды. Әлеге Әхмәд хан Русия хөкемдары Иван III заманында Мәскәүгә илче җибәреп, хат белән ел саен тапшырылган җизьяләрне*** сорады. Әлеге хөкемдар үҗәтлек белән хатны атып ташлап, аягы белән таптап, илчеләрне үтереп, фәкать берсен кайтарып җибәрде. Моннан соң хан гаскәре белән әлеге хөкемдарны тәрбия бирмәк өчен Русия мәмләкәтенә һөҗүм кылып йортлары эченә кереп, талап, үтереп әсиргә алу белән Угра елгасына барып җитте. Аллаһының хөкемедер ки, шунда Русия халкы күп җыелып, зур сугыш булып, хан гаскәре җиңелеп, үзе руслар кулына төшеп, качып китеп котылса да, артыннан җитеп тотып үтереп Сарай дәүләте бөтенләй инкыйраз булып татар дәүләте 3 шөһбәгә бүленде. Берсе Казанда, берсе Хаҗитарханда, вә берсе Кырымда калды. Вә бу 908 (7.VII.1502 – 25.VI.1503) елда булды.

Рус хан улларыннан булган ханнар Тимур-Котлык ханнан бирле Туктамыш хан уллары белән аралашып килде. Вә ләкин без икесен аерып, моның турында фасыл китердек. Русия мәмләкәтендә булган хөкемдарлар һәммәсе 620 (4.II.1223 – 23.I.1224) елдан ошбу вакыттка кадәр Сарайда булган татар ханнарына буйсынып, вә дәүләтләре Сарай мәмләкәтеннән исәпләнгән бер өлеш булып торган иде. Сарай ханнарына итәгать вә түбәнчелек белән җизъия вә хараҗ бирүдә вә коллыкта иделәр. Сарай ханы тарафыннан бер мәсьәлә белән берсе килгәндә, аны Мәскәү хөкемдары юлның бер өлешен җәляүләп каршы алырга чыгар иде.

Туктамыши патшалар хакындагы фасыл

Беренчесе — Насыйреддин Туктамыш Баһадир хан бине Туйхуҗа бине Туккол-Хуҗа бине Көнҗәк бине Сарыйҗә бине Үз-Тимур бине Тукай-Тимур бине Җүҗи хан. Туктамыш хан нәселен кайберәүләр телгә алдылар, Туктамыш хан бине Туйхуҗа бине Җимтай бине Әбисан. Моңа карап Урда бин Җүҗи хан улларыннан буладыр. Аллаһы әгъләм.

Туктамыш хан татар ханнарының бөек, куәтле вә танылганнарыннандыр. 778 (21.V.1376 – 9.V.1377) елда Сыгнакны алып Ак Урда хөкемдары булды вә Насыйреддин Баһадир хан исеме үзенә кушамат итеп бирелде. Ибне Гарәбшаһ 771 (5.VIII.1369 – 25.VII.1370) елда Мавәраэннәһер хөкемдары әмир Хөсәен бине Фулад бине Кызгын әт-Төркине Тимур үтергәннән соң Туктамыш ханның ачуы килеп Тимур белән Сыгнак вә Утрар якларында сугышты, ди, Аллаһы әгъләм. Моннан соң Русханның вафатыннан соң аның улларының кулыннан Тимур-Мәлик гасырында, Тимур ярдәме белән җиңеп бөтен Җүҗи олысына патша булып Сарай шәһәрендә тәхеткә утырды. 782 (7.IV.1380 – 27.III.1381) елда акча суга башлады, бик һиммәтле, батыр, яхшы җитәкче патша иде.

Азәрбайҗанга сәфәр кылып Тәбриз вә аның тирәсен кулына алып галимнәреннән Камаледдин әт-Тәбризине Сарайга алып кайтты. Русия таифәсен җиңеп бөтенесен татарга буйсындырды, вә Тимурның йөреш вакытында Сәмәркандны барып алды. Моннан соң Туктамыш ханның әмирләреннән берсе, коңгырат кабиләсеннән Идегү мирза исемле заттан бәгъзы сәбәпләр белән рәнҗегәнен хәтеренә төшереп аны тәрбияләү максатыннан эчендә

* Сүз аңлашылмый.
** Касыйм хан.
*** Мөселман булмаганнардан җыелган салым.

EV_1_08.indb 192 13.05.2008 12:20:44

саклап калса да, бер көнне дуслык мәҗлесендә вә кәефле вакытта иде: «Бер көнне сиңа һәм миңа гаделсезлек кылып вә ризык тулы өстәлләрдән ураза белән сине икенче якка борды, вә бакый тормышка караган күзеңне фанилык төше белән тутырды», — дип. Идегү хата кылып әйтте: «Якла, әй мәүләбез хакан, үзеңә хыянәт итмәгән колыңны нәфрәт итүдән...» — дип, ханны бер вакыт адаштырып, хаҗәтен үтәргә дип чыгып китеп, бер яхшы атка атланып качып, Тимур хозурына барды.

Аны Туктамыш хан мәмләкәтенә килергә котыртып, Тимур бик тиз әзерләнеп Бәркә җирен алырга ниятләп, гаскәрнең алдында булганда Туктамышның уң як әмирләрендә бер әмирнең икенче бер әмиреннән үч алу теләге белән аерылу таләбе күрсәтеп, Туктамыш аңа әзер дошман килгәндә аның вакыты түгел дисә дә, әлеге әмир үз дигәнендә нык торып, үз кабиләсеннән булган кәвеме белән бергә аерылып китеп, Идегү белән бу әмир кирәк булганда Туктамышның канатын сындырдылар, шуның белән Туктамыш Тимур белән бер сугыш кылды, шул ук вакытта андыйны күрмәмеш иде, диләр, ләкин ахырында җиңелеп качып Ләһестан мәмләкәтенә керде. Хәзер дә ул мәмләкәттә калган иске мөселманнар Туктамыш хан гаскәреннән аерылып калган татарлардыр. Бу хәл 793 (9.XII.1390 – 28.XI.1391) елында булды.

Идегү мирза Тимурны алдап үтеп качып калды. Тимурны алдап ул туганнарының бере бу, икенчесе шәех Вәлиеддин Габдеррахман бине Хәлдун әл-Мәгъриби әл-Мәлики әл-Казый. Тимур бу мәмләкәтне талап, үтереп, әсирләр алып, утта яндырып, бөтенләй харап итеп татар дәүләтен бөтенләй көчсезләндереп зур тәфрика вә ихтилаф булды. Моннан соң Идегү мирза кавем, кабилә, ил вә күрше кабиләләрне берләштереп, гаскәр ясап, Рус хан улларыннан булган Тимур-Котлыг хан бине Тимур-Мәлик ханны патша итеп Туктамыш хан белән сугыш кылып һәрвакыт җиңелеп уналтынчы тапкыр булган сугыштан соң җиңде вә бөтенләй исеме югалып, хәбәр өзелеп Туктамышны эзләтсә дә, таба алмый, вә үлек вә терек икәнен белми ике ел үтеп төшенелгән үлеменнән соң Туктамыш ханның тыныч вә гафләт вакытында бер һөҗүм белән басып үтерү белән бөтен мәмләкәтен үз карамагына кертеп, ханнарына бары тик исем, хөтбә, акча вә бер микъдар вазифалары булыр иде. Тимур хан көннәренә кадәр шул хәл дәвам итте, вә Туктамыш хан вафаты 798 (16.X.1395 – 4.X.1396) елында булды.

Туктамыш ханның Ләһестан хөкемдары Ягайлага татар теле уйгыр язуы белән язган ярлыгы будыр:

«Туктамыш сүзем Ягайлага.

Олуг урынга утырган әркаин аңалату Кутлу Бага Хәсән башлы илчеләр әйтүйүк әрдисен тагы келчинеңне бизә әйтиң әрди борынгы ел Бикбулат Хуҗа, Мәдин башлы берничә угъланнар Бәхеш, Тотачак Бирде, Дауд башлы бәкләр Идегү атлы кешене Тимиргә алдырдин чыгарып имешләр. Ул тил берлән килде әрде, аларның ала күңел белә тил итеп илгари кыйганы дагылганда аңлап егылып санчышмага торганда ул яман кешеләр борын тиркәннән ил тартып ул эш тагы ул чаклы булган ирде, ул ирде Тәңре безне ярлыкап дошманлык кылган Бикбулат хуҗа, Мәдин Бикши, Турдучак Бирде, Давуд башлы угъланнар бәкләрне мунганалды имди. Бу аркану аңлату Хәсән Тулу хуҗа башлы илчеләрне ийитүк иде, тагы булса безгә бакар илләрне җыпкышлар белә чыгарып барган илчеләргә биргел, хәзинәгә тикүрсеннәр бәсә борынгы йусунче базарган уртакларының тагы йөрешсүнләр, Олуг Улусның турусынга тагы яхшысы ул булгай дип алтун нишанлык йарлык туттук.

Тагу ел, тарих 795 (17.XI.1392 – 5.XI.1393) тә, рәҗәп аеның сигизенки дә.

Урдудан аруда битикләдемеш»*.

Туктамыш ханның сигез улы: Җәлаледдин, Җәббар-Бирде, Кибәк, Кәрим-Бирде, Искәндәр, әбү Сәгыйть, Көчек, Кадыйр-Бирде, Туккол-Хуҗа** исемледерләр. Аннары улы

* Бу ярлык оригинал телендә бирелә (чагыштырыр өчен кара: Радлов В. Ярлыки Токтамыша и Темир-Кутлуга // Записки восточного отделения Императорского русского археологического общества. – 1888. – Т. 3. – С. 1-40; Тарханные ярлыки Тохтамыша, Тимур-Кутлука и Саадет-Гирея с введением, переписью, переводом и примечаниями, изданные И. Березиным. – Казань, 1851. – 56 с.).

** Документта шулай. Туктамышның уллары арасында Туккол-Хуҗа исемлесе юк. Монда Ш. Мәрҗани бәлки Туктамышның нәселен билгеләр өчен бабалары арасында саналган Туккол-Хуҗаны китергәндер.

EV_1_08.indb 193 13.05.2008 12:20:44

Җәлаледдин хан булды. Туктамыш уллары аталары вакыйгасыннан соң һәрбере аптырап, ватаннарын ташлап, тирә-якка таралдылар. Җәлаледдин Русия мәмләкәтенә качкан иде. Идегү мирза белән Тимур хан арасында фетнә купкач, Туктамыш хан уллары форсаттан файдаланып баш күтәреп, мирас мөлкәтләрен таләп итеп, Җәлаледдин хан 815 (13.IV.1412 – 2.IV.1413) елдан башлап ундүрт ай патша булды.

Аннары туганы Кәрим-Бирде хан булды. Биш ай патшалыгыннан соң аны туганы Җәббар-Бирде үтерде. Аннары туганы Җәббар-Бирде хан булды. Аннары туганы Кибәк хан булды, 827 (5.XII.1423 – 22.XI.1424) елларда булгандыр. Русия мәмләкәтендә иде. Аннары туганы Кадыйр-Бирде хан булды. Кырым, Болгар һәм башка кайбер өлкәләрдә хөкемдарлык итте. Шәһри Болгар вә Кырымда сугылган тәнкәләре бар. «Идел туңса кем кичмәс, Идегү булса кем китмәс» — дигән сүз моның мәкаледер. Кырым ханнары Туктамыш ханның туганы Түләк-Тимур улларыннандыр.

СҮЗЛЕК:

Адландыру — исем бирү.
Александр ән-Нифи — Александр Невский.
Аллаһы әгъләм — Аллаһы яхшырак белә.
Багланып — берләшеп.
Базарган — сәүдәгәрләр.
Бинаән — таянып.
Бителде — язылды.
Битикләдемеш — яздык.
Биш җомга кадәр — биш атна.
Вәзенендә — үлчәмендә.
Гад(е)л — гаделлек.
Газиләр — сугышчылар.
Гайреләр — башкалар.
Гажәместан — Иран.
Гамил — мәэмүр, берсенең буйсынуында булган.
Гасабиять хасил итеп — түземсезлек кылып.
Гыйззәт — олылау.
Дагылганда — таралганда.
Дад — гаделлек.
Дәгъвәт итте — чакырды.
Дәрья — диңгез.
Дәстүрне — канунны.
Җаир — аккан.
Җиһангирлек — җиһанны үз кулыңа алу.
Зате шәрифедә — үзендә, гәүдәсендә.
Иртидад — диннән кайту.
Ислах — төзәтү.
Итагать астына кертте — буйсындырды.
Ихсан — яхшылык.
Ихтилалга — буталчыкка.
Ихтилаф — аерма.
Йөреш — поход.
Казыел-козат — казыйларның казыйсы.
Кайсари Руми суләләсеннән — Византия патшалары нәселеннән.
Капы кулы — сакчысы.
Кәнарында — кырында.
Куланч гыйлләте — каты эч авыртуы.
Куркан — хан нәселеннән берсенә өйләнгән кеше. Хан кияве.

EV_1_08.indb 194 13.05.2008 12:20:45

Кустантинияга — Константинополь, хәзерге Истанбул.
Лал — рубин.
Ләһестан — Польша.
Мәлик — патша.
Монлар анлар — болар алар.
Мөлкәт — хакимият.
Мөнасип — уңай.
Мөрафәга — суд, мәхкәмә.
Мөрәббә — кайнатма.
Мөшәррәф булдылар — шәрәфләнделәр.
Наип — урынбасар.
Нитәкем — хәлбуки.
Нишанлык — тамгалык.
Ниязнамә — ялвару хаты.
Нугай таифәсе — нугай халкы.
Нукай — Нугай.
Рәгыйять — кара халык, гади халык.
Рәсүлүлла — Мөхәммәд пәйгамбәр.
Сәйидемез — Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән булган кеше.
Сәфинәләр — кораблар.
Та — озак вакытны белдерү.
Таифә — төркем.
Тасниф итеп — классификацияләп, сыйныф-бүлекләргә бүлеп.
Тәкирмәсүн — тимәсен.
Тәсаррыф — күрсәтмә бирү, идарә итү.
Тәфрика — бүлү, таркату.
Төшенелгән — фаразланган.
Фасыл — бүлек.
Халәт — хәл.
Хан хозурына — хан каршына.
Ханә — өй.
Хәраҗ — салым.
Һәвәс — теләк.
Һидият — туры юл.
Шәрех — аңлатма.
Шәриф — хөрмәтле.
Шөһбә — бүлек.
Яран — якын.

Текстны басмага
тарих фәннәре кандидаты
Илнур Миргалиев,
Альберт Исмәгыйлев
әзерләделәр

РЕЗЮМЕ
Публикация кандидата исторических наук И. Миргалеева и А. Исмагилова посвящена труду Ш. Марджани «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (Кладезь сведений о делах Казани и Булгара), написанному арабским шрифтом на старотатарском языке. Публикаторами подготовлен перевод той части работы Ш. Марджани, которая относится к истории Золотой Орды.

EV_1_08.indb 195 13.05.2008 12:20:45